■ Белгәндәребез дөресме?

# ХӘДИС ЯТЛЫЙМ

## "Мөселман - кулы һәм теле белән башка мөселманнарга зыян китермәгән кеше"

Идеаль мөэмин, чыннан да, тынычлык, сәламәт һәм иминлек атмосферасы эченә кереп, шул атмосферада үзен эретә алган... Һәм янә үзе кебек чын мөэминнәргә кулы вә теле белән зыян китермәгән кеше. Шулай күренгән яки үзен шулай дип санаган кешеләрне түгел, бөтен зиһеннәргә рәсеме төшерелгән камил вә идеаль мөэминне аңлата бу хәдис. Без лямы тәгърифнең килүеннән моны аңлыйбыз. Ягни мөэмин дигәндә иң беренче акылга килгән камил мәгънәдәге мөэмин вә хәдистәге мөэминнән максат та бу.

Гади бер кешенең грамматикадагы бу нечкәлекне белүе мөмкин түгел. Чөнки эшнең бу ягы мәктәп, мәдрәсә яки бер укытучыдан дәрес алып өйрәнелгән грамматика гыйлеме белән мөмкин. Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) мондый бер укуга мохтаҗ түгел иде. Чөнки ул Мөгаллими әзәлнең (мәңге укытучы) Аллаһның сөйләгәннәрен сөйли иде. Шуның өчен Аллаһның Рәсүле (с.г.в.)нең әйткән бөтен сүзләрендә тел өчен кирәк булган бөтен белемнәр бар...

Югарыда әйтелгән хәдис буенча, чын мөселман - ышанычлы һәм имин кеше. Бөтен кешеләр зәррә микъдары булса да аңардан шикләнмәсләр һәм аның турында:

"Бу кешедән безгә бернинди зыян килмәс", - дигән уйда булырлар. Хәтта гаиләләрен берәүгә калдырып китәргә кирәк булган вакытта да, йөрәкләре бик тыныч булып, аңа әманәт итеп калдырырлар вә бернинди кайгыру да аларда булмас. Чөнки аның кулыннан һәм теленнән берничек тә зыян килмәячәген белерләр. Аның белән бер мәҗлестә утырып сөйләшсәләр, өйләренә кайтканда йөрәкләре бик тыныч булыр. Чөнки беләләр ки, иптәше алар артыннан үзе гайбәт ясамаганы кебек, башкаларның ясавын да тыңламас.

Ул һәрвакыт үз намус һәм шәрәфен саклаганда күрсәткән игътибарны башкаларының намус һәм шәрәфен саклау мәсьәләсендә дә күрсәтер. Күп вакытлар үзе ашамас - ашатыр, эчмәс - эчерер. Бөтен бу мәгънәләрне лямы тәгърифнең билгелек белдерә торган үзенчәлегеннән аңлыйбыз.

### ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ МӨСЕЛМАН

Башка яклап караганда, "мөслим" сүзе белән "сәлимә" фигыле икесе бер тамырдан чыкканнар. Кайбер хәрефләренең бер-берсенә охшавы аркасында, бөтенләй булмаса да, бер-берсенә охшаган яклары бар. Ләкин бу ике сүз аерым-аерым баблардан чыккан. Бу бер-берсенә охшау белән аерым баблардан чыгуы безгә шул мәгънәне аңлата.

Мөселманның һәр мәсьәләсе тынычлык, сәламәт һәм мөслимлек юлында булыр. Ул үзен шундый бер илаһи юлга керткән ки, аның хәрәкәтләре куввәи иләл мәркәзиядә (илаһи мәркәзгә бәйләнешле) барлыкка килер.

Ул таныган-танымаган бөтен кешегә сәлам бирер. Шуның аркасында Аллаһ Тәгалә тарафыннан күңелләрдә аны ярату хисе куелыр.

Намазын бетергән вакытта да сәлам белән бетерер. Инсан, җен, фәрештә - бөтен мәхлуклар аның сәлам бирүенә җавап бирерләр. Ул күрмәгән бу барлыклар белән сәламләшер. Мөэмин кешедән башка сәламне бу рәвештә таратучы башка бер кем дә булмады.

Исламга намаз, ураза, зәкят, хаҗ һәм кәлимәи шәһадәт кебек рөкеннәрне җиренә җиткереп эшләү белән керелер. Бу Аллаһу Тәгаләнең "бөтенегез бергә тынычлыкка керегез" әмеренә ияру белән тынычлык һәм сәламәт диңгезендә җилкән киерү димәк. Ул диңгездә җилкән киергән кешенең һәр хәленнән тынычлык һәм ислам исләре килер. Бу халдә булган бер мөселманда изге гамәлдән башка бернинди хәрәкәт күренмәс.

### НИ ӨЧЕН КУЛ ҺӘМ ТЕЛ?

Әфәндебез (с.г.в.)нең, һәр сүзендә булган кебек, бу сүзендә дә кулланылган һәрбер сүз игътибар белән әйтелгән. Бу урында кул һәм тел хакында сүз бара. Башка әгъзаларның түгел, тик бу ике әгъзаның әйтелүендә, әлбәттә, бик күп хикмәтләр бар.

Кеше башкаларга зарарны ике төрле бирә. Бу виҗаһи (ачыктан ачык) яки гыяби (артыннан) булырга мөмкин. Виҗаһи зарар - кул, гыяби - тел белән эшләнә. Кеше каршысындагы кешегә ачыктан ачык золым итәр һәм аның хокукы санамас, яки артыннан сөйләү белән гайбәтен ясап, аның кешеләр арасындагы дәрәҗәсен төшереп, хокукына зыян китерер. Бу ике ямьсез хәл мөэмин кешедә беркайчан булмас. Чөнки ул алдында әсир булган кешеләргә дә, алдында булмаганнарга да, һәрвакыт мөрәүвәт (кешелек) белән хәрәкәт кылыр.

Аеруча Әфәндебез (с.г.в.) телне кулдан алда әйтә. Чөнки кул белән эшләнүе мөмкин булган зарарга каршыдагы кешенең җавап бирү ихтималы бар. Ләкин кеше артыннан кылынган гайбәт яки яла ягу, күбесенчә, җавапсыз калыр. Мондый хәрәкәт кылу күп вакытлар кешеләрне, гаиләләрне, җәмгыятьләрне, хәтта милләтләрне бер-берсенә дошманлыкка кертер. Тел белән зыян китерүчеләрне эзләп табу һәм аларга лаек җәзалар бирү бик җиңел түгел. Шуның өчен Әфәндебез (с.г.в.) телне кулдан алда әйткән.

Икенче яктан, бу хәдистә мөселманның Аллаһ катындагы кыйммәт һәм дәрәҗәсенә ишарә ителгән. Мөселман булуның Аллаһ катында шундый бер кыйммәте бар ки, башка бер мөселман аңа каршы кулын һәм телен контрольдә тотарга тиеш.

Бөтен җиһанга иминлек һәм тынычлык хисләре белән килгән Ислам диненең бик мөһим әхлакый ягы - мөселман бер кешенең үзенә матдимәгънәви зыян китерүе мөмкин булган бөтен нәрсәләрдән ераклашуы, башка әһәмиятле тирәнлеге белән бүтәннәргә аз гына да зарар бирмәведер. Хәтта зарар бирү түгел, нинди халык булса да, аларның арасына иминлек һәм тынычлыкны таратуда Исламның вәкиле булырга тиеш.

Әйе, күкрәгендәге иминлек хисләре һәм йөрәгенең ышанычлык белән сугуы үлчәүле кеше чын мөселман. Һәм чын мөселман йөрәген урыннарда вә яшәгән халыклар арасында "әссәлам" чыганаклы бу хисләрне аңлатучы кеше. Ул мөэминнәр белән очрашкан вакытта аларга сәлам бирер һәм иминлек таратыр. Алардан аерылган да исәнлек теләкләре белән аерылыр. Намазда Тәхыятне сәлам белән бизәр. Һәм Аллаһның хозурыннан аерылган вакытта да мөэминнәрне сәламләү белән аерылыр. Шулай итеп бөтен тормышын сәлам тирәсендә үткәргән бер кешенең шушы төп уйга каршы килеп иминлеккә, ышанычка, матди-мәгънәви, дөньяви-ухрәви сәламәтлеккә зыян китерә торган бер юлга керүе үзенә һәм башкаларга зарар бирүе мөмкин түгел.

Хәдиснең мәгънәсен болай өстән генә әйткәннән соң, аның рухыннан чыккан шул хосусларга игътибар кылырга кирәк:

1. Чын мөселман җир йөзендә бөтен җиһанның тынычлыгын саклаучы имин бер вәкил.
2. Мөселман үзенең күңелендә булган бу олы хисләрне бөтен якта тарату белән вазифалы.
3. Ул халык арасында явыз кеше буларак түгел, хакны, гаделлекне, иминлек һәм тынычлыкны таратучы кеше буларак танылыр.
4. Аныңча, кул белән зарар китерү һәм гайбәт, ифтира (ялга ягу) хурлау, кимсетү, сүз йөртү, мыскыллау кебек гөнаһлар арасында аерма юктыр. Хәтта кайбер хәлләрдә икенчесе беренчесеннән тагы да зуррак хата дип саналыр.
5. Бер мөэмин бу гөнаһлардан берсен эшләгән булса, янә мөэминдер һәм диннән чыкмас. Ягъни гакыйдәбез буенча, кәфер-иман арасында бер урын юк.
6. Һәр мәсьәләдә булган кебек, иман һәм Ислам мәсьәләсендә дә гади генә бер мөселман булуны түгел, камил мөэмин булуны сорау кебек бик күп хакыйкать бу хәдистә бер генә юл белән аңлатылган.

### Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл ахыр 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Йомадиәл ахыр | Аҙна көндәре | май, июнь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүшәмбе | 4 | 5.04 | 6.34 | 14.30 | 20.23 | 21.53 | 23.23 |
| 2 | Шишәмбе | 5 | 5.02 | 6.32 | 14.30 | 20.25 | 21.55 | 23.25 |
| 3 | Шаршамбы | 6 | 5.00 | 6.30 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.26 |
| 4 | Кесе йома | 7 | 4.58 | 6.28 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.28 |
| 5 | Йома | 8 | 4.56 | 6.26 | 14.30 | 20.30 | 22.00 | 23.30 |
| 6 | Шәмбе | 9 | 4.54 | 6.24 | 14.30 | 20.32 | 22.02 | 23.32 |
| 7 | Йәкшәмбе | 10 | 4.52 | 6.22 | 14.30 | 20.34 | 22.04 | 23.34 |
| 8 | Дүшәмбе | 11 | 4.50 | 6.20 | 14.30 | 20.36 | 22.06 | 23.36 |
| 9 | Шишәмбе | 12 | 4.48 | 6.18 | 14.30 | 20.37 | 22.07 | 23.37 |
| 10 | Шаршамбы | 13 | 4.46 | 6.16 | 14.30 | 20.39 | 22.09 | 23.39 |
| 11 | Кесе йома | 14 | 4.45 | 6.15 | 14.30 | 20.41 | 22.11 | 23.41 |
| 12 | Йома | 15 | 4.43 | 6.13 | 14.30 | 20.43 | 22.13 | 23.43 |
| 13 | Шәмбе | 16 | 4.41 | 6.11 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 23.44 |
| 14 | Йәкшәмбе | 17 | 4.39 | 6.09 | 14.30 | 20.46 | 22.16 | 23.46 |
| 15 | Дүшәмбе | 18 | 4.38 | 6.08 | 14.30 | 20.48 | 22.18 | 23.48 |
| 16 | Шишәмбе | 19 | 4.36 | 6.06 | 14.30 | 20.49 | 22.19 | 23.49 |
| 17 | Шаршамбы | 20 | 4.35 | 6.05 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 18 | Кесе йома | 21 | 4.33 | 6.03 | 14.30 | 20.53 | 22.23 | 23.53 |
| 19 | Йома | 22 | 4.32 | 6.02 | 14.30 | 20.54 | 22.24 | 23.54 |
| 20 | Шәмбе | 23 | 4.30 | 6.00 | 14.30 | 20.56 | 22.26 | 23.56 |
| 21 | Йәкшәмбе | 24 | 4.29 | 5.59 | 14.30 | 20.57 | 22.27 | 23.57 |
| 22 | Дүшәмбе | 25 | 4.27 | 5.57 | 14.30 | 20.59 | 22.29 | 23.59 |
| 23 | Шишәмбе | 26 | 4.26 | 5.56 | 14.30 | 21.00 | 22.30 | 00.00 |
| 24 | Шаршамбы | 27 | 4.25 | 5.55 | 14.30 | 21.02 | 22.32 | 00.02 |
| 25 | Кесе йома | 28 | 4.24 | 5.54 | 14.30 | 21.03 | 22.33 | 00.03 |
| 26 | Йома | 29 | 4.23 | 5.53 | 14.30 | 21.05 | 22.35 | 00.05 |
| 27 | Шәмбе | 30 | 4.21 | 5.51 | 14.30 | 21.06 | 22.36 | 00.06 |
| 28 | Йәкшәмбе | 31 | 4.20 | 5.50 | 14.30 | 21.07 | 22.37 | 00.07 |
| 29 | Дүшәмбе | 1 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.09 | 22.39 | 00.09 |
| 30 | Шишәмбе | 2 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.10 | 22.40 | 00.10 |

# МОСОЛМАН ТОРМОШОНДАҒЫ ИҢ ОЛО ДЖИҺАД

Мөьминдәр алып барған һәм пәйғәмбәребеҙ үҙе лә ҡатнашҡан һуғыштарҙың иң ауыры Тәбүк һуғышы була. Бындай яуға сығырға мосолмандарҙы тормош үҙе мәжбүр итә. Төрлө алыштарҙа яулап өлгөргән уңыштарын ҡулдан ысҡындырмау маҡсатында Византия императоры көс туплай, мосолмандар хәл алып, көс туплап өлгөргәнсе бөтә Ғәрәбстанды ҡулға төшөрөү сараһын күрә башлай.

Был ҡанлы һуғышта ҡатнашыу өсөн Исламды ҡабул итеп өлгөрмәгән ғәрәптәрҙә лә файҙаланырға теләй.

Был хәбәрҙәр, әлбиттә, мосолмандарға ла килеп етә һәм пәйғәмбәр румдарға ҡаршылык күрһәтеү сараһын күрә, ғәскәр туплай.

Йәйҙең ғәрәптәр үҙҙәре лә түҙеп тора алмаҫ эҫе көндәре була был. Юлдар оҙон һәм ауыр, дошман көслө.

Сәфәр бик ауыр шарттарҙа үтә. Мең сакрымдан артыҡ юл йөрөп, Мәҙинәгә ҡайтҡанда мосолмандарҙы танырлыҡ та булмай: аслыҡтан тиреләре һөйәктәренә йәбешеп, сәстәре туҙғып бөткән була.

Шул саҡта пәйғәмбәребеҙ бөтәһен дә таң ҡалдырып: "Беҙ кескәй генә бер джиһадтан ҡайтып килабеҙ", - тип белдерә.

- Эй, Аллаһ илсеһе! Беҙҙең ниндәй хәлдә булыуыбыҙ һәр кемгә билдәле. Бынан да олораҡ джиһадтың булыуы мөмкинме, - тиҙәр сахәбәләр.

- Мөмкин, - ти пәйғәмбәр, ғәләйһис-сәләм. - Беҙ джиһадтың иң олоһо - үҙ нәфсебеҙ менән көрәшеп башларға тейешбеҙ.

Мөьминдәрҙең иң яҡшыһы - күркәм холоҡло булғаны".

"Саҙаҡаның иң яҡшыһы үҙең сәләмәт, малға ҡарата һөйөүҙең көслө, һаранлыҡтан да айырылмай, киләсәк тормошо уйлап, фәҡирлектән ҡурҡып йөрөгән ваҡытта бирелгәне".

"Мөьминдәрҙең иң яҡшыһы - мосолмандар - ғөмүмән, һәр кем - уның теленән дә, ҡулынан да имен булғаны".

"Мөһәжирҙәрҙең иң яҡшыһы - Аллаһы Тәғәлә тыйғандарҙан тыйыла белгәне. Һуғыштарҙың иң яҡшыһы - Аллаһы Тәғәлә ризалығы өсөн үҙенең нәфсеһенә ҡаршы тора алғаны".

Дин беҙҙе иманлы кешеләрҙән, көслө рухлы шәхестәрҙән өлгө алырға өйрәтә, түбәнлектәрҙән таралып китеүенән ҡурсалап ҡына тора. "Алма ағасынан алыҫ төшмәй", - тигән боронғолар. Төшә. Өҙөлөп төшә лә, әллә ҡайҙарға китеп боҙолоп та бөтә.

***"Дини календарь" китабынан алынды.***